# Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларының IX сыйныф укучыларына 2014 нче елда ТАТАР ТЕЛЕННӘН бердәм республика тесты уздыру өчен контроль бәяләү материалларының үзенчәлекләре (спецификация)

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан әзерләнде

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларының IX нчы сыйныф укучыларына 2014 нче елда татар теленнән бердәм республика тесты уздыру өчен контроль бәяләү материалларының үзенчәлекләре (спецификация)**

1. **Контроль бәяләү материалларының әһәмияте**

Контроль бәяләү материаллары татар телендә гомуми белем бирү оешмаларының IX сыйныфын тәмамлаучы укучыларның татар теленнән әзерлек дәрәҗәләрен бердәм республика тесты уздыру максатыннан бәяләүне күздә тота.

2. **Контроль бәяләү материаллары эчтәлеген билгели торган документлар**

Контроль бәяләү материаллары түбәндәге документларга нигезләнеп эшләнә:

1) Зәкиев М.З. һ.б. Татар телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теленнән программа (5-11 нче сыйныфлар). – Казан: Мәгариф, 2011. – Б. 36-60.

3. **Бердәм республика тестының структурасы**

Тест эше тәкъдим ителгән 4 җаваптан берсен сайлап алу мөмкинлеге булган 7 биремнән, кыска җавап бирүне таләп иткән 9 биремнән, киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән 2 биремнән – кыска изложение һәм бер альтернатив бирем – сочинениедән гыйбарәт.

Татар теленнән тест эше өч бүлектән тора.

1 нче бүлек кыска изложение язуны күздә тота.

2 нче бүлектә (А1-А7, В1-В9) җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган һәм кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәр тәкъдим ителә.

3 нче бүлектә (С2.1 яки С2.2) укылган текст нигезендә үз фикереңне белдерә алуны тикшерүгә юнәлдерелгән, киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән, ачык типтагы биремнәр үтәү (сочинение язу) каралган.

*Тест биремнәрнең бүлекләргә бүленеше*

*1 нче таблица*

| Тест эшенең бүлекләре | Биремнәрнең саны | Иң югары башлангыч балл | Бирем төрләре |
|---|---|---|---|
| 1 нче бүлек | 1 (С1) | 7 | Киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән |
| 2 нче бүлек | 7 (А1-А7) | 7 | Җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 9 (В1-В9) | 9 | Кыска җавап бирүне таләп иткән |
| 3 нче бүлек | 1 (С2) | 9 | Киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән |
| 1 нче һәм 3 нче бүлекләрдә (С1 һәм С2) | | Грамоталылык һәм сөйләмнең төгәллеге өчен 10 | |
| Барлыгы: | 18 | 42 | |

**4. Контроль бәяләү материаллары биремнәренең эчтәлеге һәм эш төрләре буенча бүленеше**

*Биремнәрнең татар теле тармаклары буенча бүленеше*

*2 нче таблица*

| Бүлекләрнең исеме | Биремнәр саны | Иң югары башлангыч балл | 42 иң югары башлангыч баллдан чыгып, әлеге бирем өчен куелган иң югары балл (процентларда) |
|---|---|---|---|
| Фонетика һәм орфоэпия | 2 | 2 | 4,76% |
| Графика һәм орфография | 1 | 1 | 2,38% |
| Лексикология һәм фразеология | 2 | 2 | 4,76% |
| Сүз төзелеше һәм ясалышы | 1 | 1 | 2,38% |
| Морфология | 3 | 3 | 7,14% |
| Синтаксис | 3 | 3 | 7,14% |
| Пунктуация | 2 | 2 | 4,76% |
| Стилистика һәм сөйләм культурасы | 1 | 1 | 2,38% |
| Татар сөйләменең сәнгатьлелеге | 1 | 1 | 2,38% |
| Бәйләнешле сөйләм үстерү:<br>-изложение (тыңланган текстның кыскача | 1<br>1 | 7<br>9 | 16,66%<br>21,44% |

| | | | |
|---|---|---|---|
| эчтәлеген язу);<br>-сочинение (бирелгән темага туры килгән эчтәлектәге текст төзү). | | | |
| Сөйләм эчтәлегенең төгәллеге һәм грамоталы булуы. | 1 нче һәм 3 нче бүлекләрдә | 10 | 23,82% |
| Барлыгы: | 18 | 42 | 100% |

Тестны язганда, укучылар төрле типтагы биремнәр үтиләр. Алар әзер тексттан тиешле материалны табып эшли, изложение яки сочинение яза.

*Тел материалы белән эшләү төрләре ягыннан тест биремнәренең бүленеше*

*3 нче таблица*

| Эш төрләре | Биремнәр саны | Иң югары башлангыч балл | 42 иң югары башлангыч баллдан чыгып, тесттагы тел материалы белән эш төрләре өчен куелган иң югары балл (процентларда) |
|---|---|---|---|
| Изложение язу | 1 | 7 | 16,66% |
| Текстта бирелгән тел материалы белән эшләү | 16 | 16 | 38,09% |
| Сочинение язу | 1 | 9 | 21,41% |
| Грамоталылык | | 10 (изложение һәм сочинение язу өчен) | 23,82% |
| Барлыгы: | 18 | 42 | 100% |

**5. Тест биремнәренең катлаулылык дәрәҗәсе ягыннан бүленеше**

*4 нче таблица*

| Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе | Биремнәр саны | Иң югары башлангыч балл | 42 иң югары башлангыч баллдан чыгып, |
|---|---|---|---|

| | | | әлеге биремнең катлаулылыгы өчен куелган иң югары балл (процентларда) |
|---|---|---|---|
| Нигез (база) | 17 | 33 | 78,57% |
| Югары | 1 | 9 | 21,43% |
| Барлыгы: | 18 | 42 | 100% |

**6. Тест эшләрен үтәү** өчен, 3 сәгать 55 минут (235 минут) вакыт бирелә.

**7. Өстәмә материаллар һәм җиһазлар**

Татар теленнән бердәм республика тесты уздыру барышында түбәндәге өстәмә материаллар һәм җиһазлар кулланыла:

1) аудиоязма тыңлау җайланмасы;
2) аудиоязма язылган компакт диск;
3) татар теленең орфографик сүзлеге.

**8. Аерым биремнәрне һәм барлык эшне бәяләү системасы**

**1 нче бүлектәге** С1 биреме (кыска изложение) махсус төзелгән критерийлар буенча бәяләнә. Аның өчен ИК1-ИК3 күрсәткече буенча иң югары балл – **7**.

**2 нче бүлектәге** һәр дөрес җавап өчен укучыга 1 балл куела. Ялгыш җавап бирелсә яки җавап булмаса 0 балл куела. Бу бүлектә дөрес җаваплар өчен укучы иң югары **16 балл** җыя ала.

**3 нче бүлектәге** С2.1 яки С2.2 биреме махсус төзелгән күрсәткечләр критерийлар буенча бәяләнә. Альтернатив бирем өчен **иң югары балл – 9.**

Изложение һәм сочинениене тикшерү нәтиҗәсе буенча укучының **грамоталылыгы** һәм язма сөйләмдәге төгәллеге өчен **10 балл** куела.

Тестның барлык биремнәрен үтәгән өчен, укучы җыярга мөмкин булган **иң югары балл – 42.**

**9. Тест уздыру шартлары (белгечләргә карата куела торган таләпләр)**

Татар теленнән бердәм республика тесты үткәрелә торган бүлмәгә татар филологиясе буенча белгечләр кертелми.

**Тестны оештыруда андагы укучылар белән эшләмәгән педагог** кына катнаша ала. Тестны бердәм таләпләр нигезендә үткәрү аның тиешле шартларын булдыруны һәм үтәүне шушы фән буенча читтән махсус белгечләр чакырмыйча да башкарырга мөмкинлек бирә.

Тест үткәрүнең **тәкъдим ителә торган тәртибе** түбәндәгечә:

1. Тест материаллары салынган пакетны алгач, укучылар бирем эшлисе бланкларга имзаларын куя, аннары аларны өстәлгә тәртибе буенча җыеп куя. Эш барышында алар тиешле формада тутырыла.

2. Башта изложение тексты аудиоязмадан тыңлана. Текстны тыңлау барышында укучыларга караламада язмалар ясау рөхсәт ителә. Икенче тапкыр текстны тыңлагач, укучылар изложение эчтәлеген кыскача язалар. Текстны тыңлау өчен аудиоязма кулланыла.

Кыска изложениене язу үрнәге:

| № | **Оештыручының эше** | **Укучыларның эше** | **Бирелә торган вакыт** |
|---|---|---|---|
| 1 | Аудиоязманы беренче тапкыр кую | Укучылар текстны тыңлыйлар, караламага кайбер сүзләрне язып баралар | 2,5 – 3 минут |
| 2 | Уйлану өчен бераз вакыт бирелә | Укучылар каралама белән эшлиләр | 3-4 минут |
| 3 | Аудиоязма икенче тапкыр куела | Укучылар текстны кабат тыңлыйлар | 2,5 – 3 минут |
| 4 | Изложение яза башлау һәм сүзлекләрдән файдалану мөмкинлеге хәбәр ителә. | | |
| 5 | | Укучылар кыска изложение язалар | |

3. Аннан соң укучыларга, тест эшенең икенче бүлеген үтәү өчен, текст таратыла. Алар тәкъдим ителгән биремнәрне үтиләр.

**Бердәм республика тестының биремнәрен үтәгәндә, укучыларга орфографик сүзлектән файдаланырга рөхсәт ителә.**

Киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнәрнең дөреслеген бердәм республика тесты уздыру буенча махсус әзерлек узган татар теле белгечләре тикшерә.

### 10. Тест уздыруга карата кайбер киңәшләр

Тестка әзерләнгәндә, укучыларга татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән гамәлдәге дәреслекләрдән, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы рөхсәте белән чыгарылган ярдәмлекләрдән, күрсәтмә материаллардан файдаланырга киңәш ителә.

**11. 2014 нче елда татар теленнән бердәм республика тесты уздыру өчен контроль бәяләү материалларының гомумиләштерелгән планы.**

2014 нче елда татар теленнән уздырылачак бердәм республика тестының эчтәлеге Кушымтада китерелгән гомумиләштерелгән планда чагылыш таба.

*Кушымта*

**2014 нче елда 9 нчы сыйныф укучыларына ТАТАР ТЕЛЕННӘН бердәм республика тесты уздыру өчен контроль бәяләү материалларының гомумиләштерелгән планы**

*Тестта һәм бланкларда биремнәрне күрсәтү: А – җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр; В – кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәр; С – киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнәр.*

*Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе: Н – нигез (база) (үтәлү вакытының 60-90%ы), Ю – югары (40% тан кимрәк вакыт эчендә үтәлә).*

| № | Тест биреме-нең билгесе | Тикшерелә торган эчтәлек элементлары | Тикшерелә торган эчтә-лек код-лары | Тик-шере-лә торган күнек-мәләр | Биремнең кат-лаулылыгы | Би-рем өчен иң юга-ры балл | Бирем-не үтәү вакыты (мин) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | С1 | Төрле стиль һәм жанрдагы текстларны эшкәртү. Текстның мәгънәви һәм компо-зицон бөтенлеге. Темага, максатка һәм аралашу ситуациясенә карап, тексттан тел чараларын сайлап алу. Төрле стильдәге текстлар төзү. Лексик, морфологик, синтаксик һәм пунктуацион нормаларны саклау. | 7.1<br>7.2<br>7.3<br>8.1<br>8.2<br>8.3<br>8.4 | 1.2<br>1.3<br>3.1<br>3.2<br>3.3<br>3.4<br>3.5<br>3.6<br>3.7<br>3.8<br>3.9 | Н | 7 | 90 |
| 2. | А1 | Тел берәмлеген фонетик яктан тикшерү | 1.2 | 1.1 | Н | 1 | 5 |
| 3. | А2 | Тел берәмлеген фонетик яктан тикшерү | 1.2 | 1.1 | Н | 1 | 5 |
| 4. | А3 | Сузык аваз хәрефләренең дөрес язылышы | 2.1 | 3.7 | Н | 1 | 5 |
| 5. | А4 | Тел берәмлеген лексик яктан тикшерү | 3.1 | 1.1 | Н | 1 | 5 |
| 6. | А5 | Тел берәмлеген лексик яктан тикшерү | 3.1 | 1.1 | Н | 1 | 5 |
| 7. | А6 | Тел берәмлеген ясалышы ягыннан тикшерү | 4.2 | 1.1 | Н | 1 | 5 |
| 8. | А7 | Тел берәмлеген морфологик яктан | 5.1 | 1.1 | Н | 1 | 5 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | тикшерү | | | | | |
| 9. | B1 | Тел берәмлеген морфологик яктан тикшерү | 5.1 | 1.1 | Н | 1 | 5 |
| 10 | B2 | Язуда пунктуациянең төп кагыйдәләрен саклау | 7.2 | 3.7 | Н | 1 | 5 |
| 11 | B3 | Сөйләмнең сәнгатьлелеге (сөйләмгә куела торган таләпләр) | 8.3 | 3.8 | Н | 1 | 6 |
| 12 | B4 | Тел берәмлеген морфологик яктан тикшерү | 5.1 | 1.1 | Н | 1 | 4 |
| 13 | B5 | Тел берәмлеген синтаксик яктан тикшерү | 6.10 | 3.6 | Н | 1 | 5 |
| 14 | B6 | Тел берәмлеген синтаксик яктан тикшерү | 6.7 | 1.1 | Н | 1 | 5 |
| 15 | B7 | Тел берәмлеген синтаксик яктан тикшерү | 6.2 | 1.1 | Н | 1 | 5 |
| 16 | B8 | Язуда пунктуациянең төп кагыйдәләрен үтәү | 7.3 | 1.1 | Н | 1 | 5 |
| 17 | B9 | Тел берәмлекләрен стилистик яктан тикшерү | 8.3 | 3.3 | Н | 1 | 5 |
| 18 | C2 | Төрле стиль һәм жанрдагы текстларны эшкәртү һәм төзү. Текстның мәгънәви һәм композицон бөтенлеге. Темага, максатка һәм аралашу ситуациясенә карап, тексттан тел чараларын сайлап алу. Төрле стильдәге текстлар төзү. Лексик, морфологик, синтаксик һәм пунктуацион нормаларны саклау. | 7.2<br>7.3<br>8.1<br>8.2<br>8.3<br>8.4 | 1.2<br>1.3<br>3.1<br>3.2<br>3.3<br>3.4<br>3.5<br>3.6<br>3.7<br>3.8<br>3.9 | Ю[1] | 7 | 65 |
| Барлыгы 18 бирем, шуларның 7 се – А, 9ы – В, 2 се – С тибында;<br>Катлалулылык дәрәҗәсе буенча 17се – нигез, 1 се – югары катлаулылыкта.<br>Эшне үтәү өчен бирелә торган вакыт – **235 минут.** | | | | | | | |

[1] С1, С2 биремнәрен тикшергәндә грамоталык һәм сөйләмнең төгәллеге изложение белән сочинение тикшерүгә нигезләнеп башкарыла һәм 10 баллга тигез.